Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение
«Высокогорский детский сад «Солнышко»
Высокогорского муниципального района Республики Татарстан

# КОНКУРС ЧТЕЦОВ АВТОРСКИХ СТИХОТВОРЕНИЙ «БӘХЕТЛЕ БАЛАЧАК»

**“Бәхетле балачак!” җыры яңгырый.**

**Сәхнәдә Незнайка күренә. Ул нәрсәдер эзли.**

**Незнайка:** Исәнмесез! Балачак иленә дөрес килеп эләктемме мин?

**Сәхнәдә язылган исемне иҗекләп укый.**

**Незнайка: “**Бә-хет-ле ба-ла-чак”**...** Дөрес килгәнмен ахырысы, “Бәхетле балачак” дип язылган. Знайка мине гел орыша инде, берни белмисең, ди. Шуңа да Балачак иленә сәяхәткә җибәрде, анда яшәүче балаларны карап, алардан үрнәк алып кайт, ди. Монда яшәүчеләр бик тапкыр, тырыш һәм акыллы балалар икән...

**Сәхнәгә алып баручылар чыга.**

**1 а.б.:** Дөрес әйтәсең, Незнайка. Безнең Балачак илендә балалар – һәр җирдә үрнәк. Сине дә бәйрәмебезгә кунакка чакырабыз. Безнең балаларны күреп, сокланып кит.

**Незнайка:** Бик рәхәтләнеп, мин бәйрәмнәр яратам.

**2 а.б.:** Хәерле кич, хөрмәтле әти-әниләр, әби-бабайлар, апалар-абыйлар, энеләр-сеңелләр, килгән кунаклар! Бәйрәмебезне ачык дип игълан итәбез!

**1 а.б.:** Күрәсезме, ишетәсезме, табигатьтә яз тантана итә! Көннән-көн табигать бар җиһанны матурлыкка күмәргә нияте барлыгын сиздерә. Яз – безнең тыйнак тормышыбызга яңа көч, дәрт, омтылыш, ышанычлар алып килә торган вакыт.

**2 а.б.:** Яз сулышы гаиләгезгә муллык алып килсен, күңелегезгә сабырлык, барчагызга саулык китерсен. Аллаһ сезне шәфкатеннән, рәхимлегеннән ташламасын, теләкләрегезне тормышка ашырырга ярдәм итсен, өстәлләрегез ямьле, аш-суларыгыз тәмле, бәйрәмнәр мөбәрәк булсын!

**1 а.б.:** Бәйрәмебезне ачып җибәрү өчен сүзне бакчабызның яшь сандугачы Имилиягә бирәбез. Рәхим ит, Имилия.

**Имилия башкаруында җыр – “Хәерле көн”.**

**1 а.б.:** без бәйрәмебезне “Бәхетле балачак” дип атадык. Ә балачак шатлык-сөенечләргә тулып торсын өчен гаилә җылысы кирәк, димәк бүген гаилә бәйрәме дә, шулай бит?

**2 а.б. :** Дөрес әйтәсең! Гаилә - ул яраткан эшеңнән соң, йөрәгеңә тынычлык, шифа бирә торган изге җир. Гаилә – ул дөнья мәшәкатьләреннән, борчулардан ял итә торган урын. Гаилә җимеше ул - балалар, сезнең нәниләрегез һәм безнең уртак шатлыкларыбыз.

**1 а.б.:** Ягез сез дә кушылыгыз
Утырмагыз, торыгыз
Җырлый-җырлый биик әле
Сез кул чабып торыгыз.

**Закирова Даяна башкаруында шигырь “Тырыш акбай”**

**1а.б.:** Без кабызган ал учаклар -
Балачак учаклары!
Ялкын төсле балкып торыр
Гомернең ул чаклары.

**2 а.б.:** Якты өсти ул учаклар
Иң якты теләкләргә.
Учаклардан күңелгә ут
Алабыз йөрәкләргә!

**1.а.б. :** Сәхнәбез түрендә үзләренең “Татар биюе” белән татар төркеме балалары. Рәхим итегез, кызлар.

**Самир башкаруында шигырь “Азат мәктәпкә бара”**

**1 а.б. :** Калфак кигән кыз баланың
Багып алчы йөзенә.
Нинди матур татар кызы!
Күз тимәсен үзенә.
Килешеп тора түбәтәй
Аның күркәм йөзенә.
Нинди батыр татар улы!
Күз тимәсен үзенә.
Зур булгач та шулай калыр
Татар баласы булып.
Әйтерләр: “Татар кызы бу!”
Диярләр: “Татар улы!”

**“Кәләпүшем-калфагым” җыры.**

**2 а.б.:**

Без биибез тыпыр-тыпыр,

Без биибез тып та тып.

Бер башласак бик тиз генә

Булмас безне туктатып.

**2 а.б.:**

Сездә безгә кушылыгыз,

Без шатлык таратабыз.

Тирә-янны яңгыратып

Җырларга яратабыз.

**Җыр “Рәхмәт, әнием”.**

**Ясминә башкаруында шигырь “Тауда”**

**1 а.б.:** Яңгырасын көйләр, шат көлүләр,
Тирә-юньгә бүген таралсын.
Кемнәр болар-бәхетлеләр диеп,
Бөтен кеше безгә карасын.

**2 а.б.:** Тыпыр-тыпыр тыпырдашып
Бергә басаек әле.
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп

**Исхакова Ясмина башкаруында шигырь “Минем гаиләм”**

**1 а. б.** Кадерле тамашачылар! Бәхетле яшәгез, матур уңышларга ирешегез, күкләребез һәрчак аяз булсын. Балаларыбыз гел сөендереп торсын!

**2 а.б.:** Шушының белән әзерләнгән концертыбыз тәмам. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!











